**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**АЕШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423741, Аеш авылы,
Ленин ур., 34б нчы йорт.
Тел.3-44-41

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423741, село Аишево,
ул. Ленина,дом 34б,
Тел. 3-44-41

КАРАР | ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№18 | 01.11.2019

Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлегенең торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Аеш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Аеш авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 20нче ноябрь көненә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

- авыл җирлеге торак пунктларында урам электр лампаларын алыштыру һәм ремонтлау;;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:Аеш авылының Ленин һәм Татарстан урамнарына ташлы ком салу һәм грейдер белән тигезләү;
--авыл җирлеге урамнарын карап тоту: грейдер белән тигезләү һәм кардан чистарту;
- авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү эшләре: Аеш авылының “Сабантуй” ял паркы территориясен төзекләндерү;
---су челтәрләрен һәм су белән тәэмин итү чыганакларын карап тоту, су алу җайланмаларын документаль рәсмиләштерү (лицензияләү);

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Аеш авылы, Ленин урамы, 34б йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Аеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы А.И.Фазлыкаева